Корбан, Р. Әхмәров: роман-хроника / Рафис Корбан // Казан утлары. – 2019. – №1 (1167). – Б. 9-53; № 2. – Б. 8-48.




...Исхак Уайт белән очрашуның бөтен ничкәлекләрен берәмтекләп күздзә кичерде. Кайда очрашырга? Очрашу турында ничек сөйләшергә? Үзеңне кем дип таныштырырга? Кем аркылы элемтәгә керергә? Гомумән, ничек элемтәгә керергә? Бәлки турыдан-туры үзенә телефоннан шатлыратып сйләшергәдер? Ул очракта, нинди телефоннан? Урамнанмы, берәр йорттанмы? Ни өчен мин Япония-Америка мәсьәләләре турында борчылам, һәм ни өчен моны ниндидер чит кешк аркылы ңиткерәм? Кыскасы, сорауларның берсен дә Исхак из игътибарыннан читтә калдырмады. Барсын да Уайтта шик тудырмаслык итеп башкарып чыгарлык дәрәҗәдә хәзерләргә тырышты...

Бу өзек Рафис Корбанның “Әхмәрев” дип исемләнгән яңа романыннан.



Исхак Әхмәров Оренбург губернасының Троицк шәһәрендә (хәзерге вакытта Чиләбе өлкәсе) 1901 елның 7-нче апрелендә туа. 1913 елдан алып 1921 елга кадәр ул Казанда яши, 1935 елга кадәр – Мәскәүдә. Соңрак разведчик тормышында иң мөһим чор балшана. 1945 елга кадәр ул АКШ-та яшерен резидентураны җитәкли. Аның агентлары СССР өчен иң мөһим булган мәгълүматлар туплый, шул исәптән “Манхэттен проекты” буенча атом коралы әзерләү турындагы материаллар. Исхак Әхмәров “Кар” (“Снег”) операциясенең башлап җибәрүчесе буларак та билгеле. Әлеге операция совет разведкасының тарихында иң әйбәт операцияләрнең берсе булып санала, аның максаты - Япония белән сугыш булдырмаска.

Бөек Җиңүгә зур өлеш керткән Исхак Әхмәров турында Рафис Корбанның романын сез “Казан утлары” журналының 1 һәм 2 саннарында укый аласыз.